ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**19.07.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1690**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 4 декабрендәге 2335 номерлы карары белән расланган, авыл территорияләрендә яшәүче һәм эшләүче,яисә даими яшәү урынына күчәргә һәм район чикләрендә эшләргә теләк белдергән гражданнарның торак шартларын яхшыртуга социаль түләүләр (субсидияләр) бирү буенча, шул исәптән Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында социаль түләүләр (субсидияләр) алучылар исемлегенә кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законына, Тааатарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 4 декабрендәге 2335 номерлы карары белән расланган, Авыл территорияләрендә яшәүче һәм эшләүче, яисә даими яшәү урынына күчәргә һәм район чикләрендә эшләргә теләк белдергән гражданнарның торак шартларын яхшыртуга социаль түләүләр (субсидияләр) бирү буенча, шул исәптән Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында социаль түләүләр (субсидияләр) алучылар исемлегенә кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1) 1 бүлекнең 1.3 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтүне башкаручы - «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» муниципаль казна учреждениесе (алга таба-Бүлек)»;

1.2) 1 бүлекнең 1.3.1 пунктындагы өченче абзацында «203 кабинеты» сүзләрен «109 кабинеты» сүзләренә алмаштырырга.

1.3) 1 бүлекнең 1.3.1 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Белешмә өчен телефон: (84371) 5-74-13».

1.4) 1 бүлекнең 1.4 пунктының унбишенче абзацында « Зеленодольск муниципаль район Советының 2018 елның 29 мартында кабул ителгән 279 номерлы карары (Зеленодольск муниципаль районы Советының 04.03.2019 ел, № 367, 27.01.2020 ел, № 482 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.5) 1 бүлекнең 1.4 пунктындагы уналтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «ЗМР торак сәясәте департаменты МКУ боерыгы белән расланган, Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба - Кагыйдәләр)»

1.6) 2 бүлекнең «Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге» графасындагы 2.2 пунктында икенче абзацын түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә: «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» муниципаль казна учреждениесе;

1.7) 2 бүлекнең «Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге» графасындагы 2.6 пунктының 4 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

1.8) 2 бүлекнең «Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге» графасындагы 2.7 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. яшәү урыны буенча теркәлү турында белешмәләр»;

1.9) 2 бүлекнең «Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге» графасындагы 2.7 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. аерым затның үзендә булган күчемсез мөлкәт объектларына хокуклары турында, Россия Федерациясе территориясендә аны алу буенча алыш-бирешләр гамәлгә ашыру хакында Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән белешмә кәгазе».

1.10) 3 бүлекнең 3.4.1 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) яшәү урыны буенча теркәлү турында белешмәләр»;

1.11) 3 бүлекнең 3.4.1 пунктындагы 3 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

1.12) 3 бүлекнең 3.4.1 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) «Аерым затның үзендә булган күчемсез мөлкәт объектларына хокуклары турында, Россия Федерациясе территориясендә аны алу буенча алыш-бирешләр гамәлгә ашыру хакында Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә

хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән белешмә кәгазе».

1.13) 5 бүлекнең 5.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.10. Шикаятьне карап тикшерү барышында яисә нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яисә җинаять билгеләре ачыкланган очракта, 2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.2 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, вазыйфаи зат, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән хезмәткәр, булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»

1.14) « Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары» кушымтасында «Бүлек» бүлегендә «Бүлек директоры» юлын төшереп калдырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев